Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин А.В. Туганов шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлешенең, «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 8 һәм 9 бүлекләренең аерым нигезләмәләренең, шулай ук аталган карарның, «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының, аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча, конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2020 елның 19 марты

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең

1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлешенең, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 8 һәм 9 бүлекләренең аерым нигезләмәләренең, шулай ук аталган карарның, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының, аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча, конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин А.В. Туганов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Л.В. Кузьмина мәгълүматын, яклар — гражданин А.В. Туганов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының юридик бүлеге башлыгы Э.А. Нургалиева, «Зеленодольск муниципаль районының юридик бюросы» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Н.Н. Пименова аңлатмаларын, суд утырышына

чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең закон проектлары эшләү бүлеге баш киңәшчесе Е.Е. Шехматова, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең граждан законнары бүлеге мөдире И.И. Фәттахов, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Хокук идарәсенең дәүләт хокукы һәм икътисадны норматив җайга салу бүлекчәсенең баш киңәшчесе Д.И. Абзалова, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Югары суды судьясы М.М. Сафина, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге әйдәп баручы консультанты Р.М. Сибаева чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин А.В. Туганов Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының (алга таба шулай ук — Устав) 81 статьясындагы 10 өлеше белән, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» (алга таба шулай ук — Программа) 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына

1 нче кушымтаның 8 һәм 9 бүлекләренең аерым нигезләмәләре белән, шулай ук аталган карар белән, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары белән, аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча, үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Уставның 81 статьясындагы дәгъва белдерелә торган 10 өлешендә муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) массакүләм мәгълүмат чарасының чыгу датасы күрсәтелергә тиеш дип билгеләнгән.

Программаның 8 бүлеге нигезендә, эшләрне башкару өчен күпфатирлы йортларның чиратын билгеләү критерийлары ачыкланган, шулай итеп, беренче чиратта аны гамәлгә ашыру «Торак-коммуналь хуҗалыкны үзгәртеп коруга теләктәшлек фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортлар өчен каралган. Йортларның әлеге төркеме эчендәге күпфатирлы йортларның чираты гомуми тәртиптә исәпләнгән сан рейтингы зурлыгы нигезендә формалаштырылган (1 пункт). Икенче чиратта Программаны тормышка ашыру беренче чиратка кертелмәгән башка күпфатирлы йортлар өчен каралган. Чиратлылык Программага кертелгән һәр күпфатирлы йортка индивидуаль сан рейтингын формула буенча бирү юлы белән билгеләнә, анда, аерым алганда, аңлылык (С), коммуникацияләр (К) һәм куркынычсызлык (V) коэффициентлары кертелгән. Күпфатирлы

йортларның чиратлылыгы рейтингның минималь күрсәткечләреннән максималь күрсәткечләргә нисбәте буенча (ягъни сан күрсәткече азрак булган саен, Программа нигезендә эшләр шулкадәр алданрак башкарыла) аралау юлы белән билгеләнә (2 пункт).

Программаны тормышка ашыру механизмы Программаның 9 бүлегендә билгеләнгән, аның 1 пункты нигезендә, яңадан асфальт түшәмнәрен ремонтлау (торгызу, урнаштыру) эшләрен башкару Программаны гамәлгә ашыру Планының (алга таба шулай ук — еллык План) ел саен раслана торган Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә гамәлгә ашырыла. Еллык Планга Планны раслауга кадәрге айның соңгы числосына формалашкан чиратлылыгы нигезендә программаны гамәлгә ашыруның чираттагы елына финанслау лимиты кысаларында күпфатирлы йортлар кертелә (беренче абзац); еллык Планга күпфатирлы йортлар керә, аларга карата Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты адресына Планны раслау датасына кадәрге айның соңгы көненә Программада катнашу турында күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең мөрәҗәгать итүләре (алга таба шулай ук — Мөрәҗәгатьләр) Программага кертелгән йортлар саныннан кергән (икенче абзац).

Программаның 9 бүлегендәге 2 пункты Мөрәҗәгатьтә күпфатирлы йортны еллык Планга кертүгә ачыктан-ачык ризалык булырга тиешлеген күздә тота. Күрсәтелгән Мөрәҗәгатькә күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы беркетмәсе кушып бирелергә тиеш, аның карары белән шул исәптән күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга ризалык, күпфатирлы йортта гомуми милекне куллануга ризалыкны исәпкә алып (фасад һ.б.), камералар саны, Бердәм түләү документына түләү кертүгә ризалык («Б» пунктчасы), шулай ук күпфатирлы йортны еллык Планга кертү өчен милекчеләрнең ачыктан-ачык ризалык белдерүе («Г» пунктчасы) расланырга тиеш. Шул ук вакытта әлеге беркетмәдә шулай ук йорт яны территориясен төзекләндерү эшләрен башкару кирәклеге турындагы мәсьәлә буенча милекчеләрнең ачыктан-ачык чагылдырылган карары, яисә Программаның 9

бүлегендәге шул ук пунктында санап үтелгән төзекләндерү элементларына карата мондый ихтыяҗ булмау турында карары булырга тиеш.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, гражданин А.В. Туганов Зеленодольск шәһәрендә Программага 2650 гә тигез булган рейтинг белән кертелгән һәм 175 күпфатирлы йорттан 119 урында тора торган күпфатирлы йортта яши.

Мөрәҗәгать итүче, ул яши торган йортта комплекслы капиталь ремонт ясалмаган, шуңа бәйле рәвештә Программаның 8 бүлегендәге 1 пункты нигезендә аның йорты аны гамәлгә ашыруның икенче чиратына эләгә дип күрсәтә. Йортта капиталь ремонт үткәрелүенә яки үткәрелмәвенә бәйле рәвештә чиратлылыкта мондый аерманы ул нигезсез һәм тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларына җавап бирми дип саный.

Гражданин А.В. Туганов, Программаның 8 бүлегендәге 2 пункты күпфатирлы йортлар өчен әлеге Программаны гамәлгә ашыруның чиратлылыгын билгеләүнең объектив булмаган критерийларын урнаштыра дип саный. Шулай, аңлылык (С) коэффициенты каралган, аның зурлыгы күпфатирлы йорт Советын сайлауга бәйле; җирле үзидарә органнарының хисаплар бирү буенча кисәтүләре булмауда һәм күпфатирлы йорт вәкилләре җирле үзидарә органнары уздыра торган чараларда даими рәвештә катнашучылар булып торуда чагыла торган коммуникацияләр (К) коэффициенты һәм күпфатирлы йортта видеокүзәтү системаларын урнаштыруга кворумга бәйле рәвештә куркынычсызлык (V) коэффициенты каралган.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Программаның 9 бүлегендәге 1 пункты аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми, ул ишегалды территорияләрен төзекләндерүгә булган гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруда мөһим шарт булып тора, шулай ук күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашыруның еллык Планына әлеге йортны кертү өчен Программада катнашу турында Мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү турындагы чиктән тыш зур таләпне үз өченә ала.

Гражданин А.В. Туганов фикеренчә, Программаның әлеге бүлегендәге 2 пункты эчтәлегеннән аларның күпфатирлы йортын аны гамәлгә ашыруның еллык Планына кертүгә милекчеләрнең ачыктан-ачык ризалыгы булып нәрсә санала, күрсәтелгән ризалык кая һәм нинди формада белдерелергә тиеш, шулай ук нишләп күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгыннан Программада күпфатирлы йорт чиратлылыгының рейтинг күрсәткеченә йогынты ясый торган тиешле коэффициент кына түгел, ә әлеге йортны еллык Планга кертү дә бәйле икәнлеге аңлашылмый.

Мөрәҗәгать итүче шулай ук «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары (алга таба шулай ук — Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 415 номерлы карары) һәм «“2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында” Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 февралендәге 155 номерлы һәм «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы (алга таба шулай ук — Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 218 номерлы карары) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының реквизитлары төгәл билгеләнмәвенә игътибар итә, алар, дәгъва белдерелә торган карарның реквизиты буларак, 03-03-415 номерын үз эченә алган. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының “2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында” 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карарының 1, 2 нче кушымталарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 15 ноябрендәге 2335 номерлы (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының

2335 номерлы карары) һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы (алга таба шулай ук — Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 895 номерлы карары) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының киләсе карарларында шикаять белдерелә торган карарның номеры инде 415 номерлы итеп күрсәтелгән. Шул ук вакытта, ул билгеләп үткәнчә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (алга таба шулай ук — Рәсми портал) Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 218 һәм 895 номерлы карарларының датасы һәм номерлары бөтенләй юк.

Моннан тыш, гражданин А.В. Туганов Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2335 номерлы карары 2018 елның 29 декабрендә Рәсми порталда урнаштырылган дип күрсәтә. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) ул шулай ук урнаштырылган, ләкин урнаштыру датасы күрсәтелмәгән. Норматив хокукый актны болай урнаштыруны, аның уйлавынча, тиешенчә бастырып чыгару дип санап булмый, ә бу хәл Уставның 81 статьясындагы 10 өлешенең конституциячел характерда булмавыннан килеп чыккан, аның нигезендә муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) басма массакүләм мәгълүмат чарасының гына чыгу датасы күрсәтелергә тиеш.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин А.В. Туганов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлешен, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль

программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1 нче кушымтаның 8 һәм 9 бүлекләренең аерым нигезләмәләрен, шулай ук әлеге карарны, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын, аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча, Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 32 һәм 55 статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, вазыйфаи затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә тиеш; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген социаль хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше йә аларга өстенлекләр билгеләү тыела; шәхеснең абруе дәүләт тарафыннан саклана; аны төшерү өчен бернәрсә дә нигез була алмый; һәркем торакка хокуклы, дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, түбәндәгеләр әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлеше, ул муниципаль хокукый актны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) бары тик басма массакүләм мәгълүмат чарасының гына чыгу датасы күрсәтелергә тиешлеген билгели;

— «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары, аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча;

— Программаның аерым нигезләмәләре, ә нәкъ менә:

- 8 бүлегендәге 1 пункты, Программаны гамәлгә ашыру, беренче чиратта, комплекслы капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортлар өчен каралган өлешендә;

- 8 бүлегендәге 2 пункты, аңлылык (С), коммуникацияләр (К) һәм куркынычсызлык (V) коэффициентларына бәйле рәвештә күпфатирлы йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратын билгеләүгә йогынты ясый торган критерийлар эчтәлегенең билгесезлеге өлешендә;

- 9 бүлегендәге 1 пункты, аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган һәм күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашыруның еллык Планына әлеге йортны кертү өчен Программада катнашу турында мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү турындагы таләпне үз эченә алган дәрәҗәдә;

- 9 бүлегендәге 2 пунктның «Г» һәм «Б» пунктчалары, күпфатирлы йортны Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планына кертүгә аның милекчеләренең ачыктан-ачык ризалыгы булып нәрсә саналуы, ул кая һәм нинди формада белдерелергә тиешлеге өлешендә, шулай ук Программада күпфатирлы йорт чиратлылыгының рейтинг күрсәткеченә һәм аны еллык Планга кертү күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгыннан бәйле булуының билгесезлеге өлешендә.

2. Җирле үзидарә оештыруның гомуми хокукый, оештыру һәм икътисадый принципларын билгели торган «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү максатларында җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлек уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү вәкаләтләренә ия дип каралган (17 статьяның 1 өлешендәге 1 пункты). Югарыда аталган Федераль законның 43 статьясындагы 1 өлешенең 1 пункты,

44 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты һәм 3 өлешенең нигезләмәләре буенча муниципаль берәмлек уставы муниципаль хокукый актлар системасына керә, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы тарафыннан кабул ителә һәм муниципаль хокукый актларның төрләрен, кабул итү (бастырып чыгару), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибен билгели. Шундый ук нормалар «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 өлешендәге 6 пунктында һәм 7 статьясындагы 3 өлешендә шулай ук каралган.

Шулай итеп, Уставны кабул итеп һәм әлеге Уставның 81 статьясында муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибен беркетеп, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы үзенә федераль һәм республика законнары белән бирелгән вәкаләтләр кысаларында эш иткән.

3. Уставның 81 статьясындагы 3 өлеше нигезендә, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокукый актлар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә. Китерелгән норматив нигезләмә әлеге статьяның 10 өлеше белән, шулай ук Уставның муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның үз көченә керү тәртибен регламентлый торган башка нигезләмәләре белән аерылгысыз хокукый бердәмлектә тора, ул кабул ителгән муниципаль хокукый актның алга таба үз көченә керүе өчен төп шарт буларак бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтү кирәклеген күздә тота. Шул ук вакытта Уставның 81 статьясындагы 10 өлешендә турыдан-туры мондый таләп булмау үзеннән-үзе норматив хокукый актны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтү мәҗбүри булган һәркем өчен бер булган тәртипне сакламау мөмкинлегенә юл куймый.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль

берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлеше, әлеге Карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәне исәпкә алып, кабул ителгән норматив хокукый актны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырганда аны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтүнең мәҗбүрилеге кире кагылмый һәм шуның белән кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең хокукларын юкка чыгармый, киметми һәм башкача бозмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды Уставның 81 статьясындагы 10 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану һәм аның конституциячел-хокукый мәгънәсен ачыклау Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен хокукый җайга салуны камилләштерүгә комачауламавына игътибар итә. Шуңа бәйле рәвештә Уставка басма массакүләм мәгълүмат чараларында басылып чыга (халыкка җиткерелә) торган муниципаль хокукый актлар мөнәсәбәтендә инде билгеләнгәнгә (Уставның 81 статьясындагы 9 өлешенең икенче абзацы) тиңдәш булган кабул ителгән муниципаль хокукый актны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) аны урнаштырганда бастырып чыгару (халыкка җиткерү) көнен күрсәтү мәҗбүрилеген регламентлаштыра торган нигезләмәләр кертү муниципаль хокукый актларны басма массакүләм мәгълүмат чараларында да, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми ресурсларда да бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) бертөрле алым

кулланылуга ярдәм итәр иде һәм гражданнар тарафыннан аңлауда билгесезлеккә китермәс иде.

4. Татарстан Республикасы Конституциясенең 10, 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләре буенча Татарстан Республикасында җирле үзидарә таныла һәм гарантияләнә, ул үз вәкаләтләре чикләрендә мөстәкыйль һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне халыкның мөстәкыйль хәл итүен тәэмин итә, җирле үзидарә органнары муниципаль милек белән мөстәкыйль идарә итә, җирле бюджетны формалаштыралар, раслыйлар һәм үтиләр. Шундый ук нигезләмәләр Россия Федерациясе Конституциясенең 12, 130 (1 өлеш) һәм 132 статьяларында беркетелгән.

Күрсәтелгән хокукый җайга салуга 1985 елның 15 октябрендәге Европа җирле үзидарә хартиясе (Россия Федерациясе өчен 1998 елның 1 сентябрендә үз көченә кергән) нигезләмәсе тәңгәл килә, аның нигезендә җирле үзидарә органнары үзләренең вәкаләтләре өлкәсендәге һәм нинди дә булса башка хакимият органы карамагында булмаган теләсә нинди мәсьәлә буенча үз инициативасын гамәлгә ашыру өчен законда билгеләнгән чикләрдә тулысынча ирекле эш итәләр (4 статьяның 2 пункты).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон эчтәлегеннән күренгәнчә, җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый актлар кабул ителә, алар системасына, шул исәптән, җирле администрациянең һәм башка җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының муниципаль берәмлек уставында каралган хокукый актлары керә (7 һәм 43 статьялар).

Шул ук вакытта Россия Федерациясе Бюджет кодексының 179 статьясындагы 1 пункты нигезендә муниципаль программаларны раслау турыдан-туры муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе вәкаләтләренә кертелгән.

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән, Программа кабул ителгән вакытта гамәлдә булган редакциясендә, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, әлеге Уставта җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр бирелгән Зеленодольск муниципаль районының җирле үзидарә башкарма-боеру органы булып Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тора, дип караган иде (42 статьяның 1 пункты) (алга таба шулай ук — Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты).

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәләрнең 9 статьясының 2 пункты һәм 29 статьясындагы 1 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты район бюджеты хисабына гамәлгә ашырыла торган муниципаль программаларны раслый һәм аларны гамәлгә ашыру срокларын, муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен билгели.

Шулай итеп, дәгъва белдерелә торган Программаны кабул итеп, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 статьясы (беренче өлеш) нигезләмәләренә таянып, федераль һәм республика законнары нигезендә үзенә бирелгән вәкаләтләрне дөрес гамәлгә ашырган.

5. Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (өченче өлеш) һәм Россия Федерациясе Конституциясенең 15 статьясы (3 өлеш) нигезендә, кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы теләсә кайсы норматив хокукый актлар, гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган булса, кулланыла алмыйлар.

Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, дәүләт исеменнән норматив хокукый актны гавами хакимиятнең компетентлы органы тарафыннан халыкка җиткерү таләбе хокукый билгеләнешнең гомумтанылган принцибына

бәйле, аның нигезендә дәүләтнең һәм шәхеснең мөнәсәбәтләре билгеләнә һәм җәмәгатьчелеккә хәбәр итү әлеге норматив хокукый актның кабул ителүе һәм бәян ителгән тулы текстының гамәлгә кертелергә тиешлеген аңлата. Шул очракта гына аның гамәлдә булуы кагыла торган затларга законны белмәү аны бозган өчен җаваплылыктан азат итми дигән гомумхокукый презумпция кагыла. Норматив хокукый актның гамәлдә булуы яисә булмавына карата билгесезлек аны саклауда, үтәүдә һәм куллануда бертөрлелекне тәэмин итә алмый һәм, димәк, хокук куллану практикасында каршылык китереп чыгара, аны зыянлы максатта һәм башбаштакланып файдалану мөмкинлеген тудыра, конституциячел хокукларны һәм ирекләрне яклау гарантияләрен киметә, тигезлек һәм хокук өстенлеге принципларын бозуга китерә (2012 елның 27 мартындагы 8-П номерлы Карар).

Татарстан Республикасы Конституция суды бу конституциячел күрсәтмә кеше һәм граждан хокукларын, ирекләрен яклау гарантияләренең берсе булып тора һәм ул императив характерга ия дип шулай ук берничә тапкыр билгеләп үтте (2006 елның 7 мартындагы 19-П номерлы, 2012 елның 21 февралендәге 47-П номерлы, 2015 елның 19 мартындагы 61-П номерлы һәм 2017 елның 28 апрелендәге 73-П номерлы карарлар).

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 83 статьясындагы беренче өлешенең 3 пункты һәм 103 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның Татарстан Республикасы Конституциясенә шул исәптән аларны кабул итү, нәшер итү, имзалау, бастырып чыгару яисә гамәлгә кертү тәртибе буенча туры килү-килмәвен билгели.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның үзара бәйләнештәге 47 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләре белән 44 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты эчтәлегеннән аңлашылганча, җирле үзидарә органнарының кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылган һәм федераль

закон белән таратылуы чикләнә торган белешмәләре булмаган норматив хокукый актлары тиешле муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнгән тәртиптә тулы тексты белән басылып чыкса гына гомуми танышу өчен рәсми басылып чыккан дип танылырга мөмкин, уставта шул исәптән муниципаль хокукый актларның төрләре, кабул итү (нәшер итү), рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе билгеләнергә тиеш.

Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль хокукый актларын бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм үз көченә керү тәртибе Программа кабул ителгән вакытка Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 5 мартындагы 492 номерлы карары редакциясендә) карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы белән җайга салынган. Әлеге Уставның 73 статьясындагы 3 һәм 9 өлешләре нигезендә кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль хокукый актлар аларны рәсми бастырып чыгарганнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә, ул түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

— хокукый акт текстын Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары гамәлгә куйган басма массакүләм мәгълүмат чараларында йә Зеленодольск муниципаль районы территориясендә таратыла торган башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару. Хокукый акт текстын башка басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарганда әлеге бастырып чыгаруның рәсми булуы хакында тамга булырга тиеш;

— хокукый акт текстын «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы гамәлдә, аның 81 статьясындагы 9 пунктының

4 абзацы нигезендә, муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) чыганаклары исемлегенә, элек гамәлдә булган Уставта беркетелгәннәрдән тыш, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) да керә.

Китерелгән хокукый җайга салу нигезендә «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган карары, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының аңа үзгәрешләр кертелгән барлык башка карарлары кебек үк, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районында муниципаль норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару чыганагы буларак билгеләнгән интернет-ресурсларда аларның текстларын урнаштыру юлы белән рәсми бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) (алга таба — «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтлар).

Шул ук вакытта, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2015 елның 5 мартындагы 492 номерлы карары редакциясендә) карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 73 статьясындагы 4 һәм 9 өлешләре нигезендә, һәр муниципаль хокукый актта аның реквизитлары, шул исәптән, исеме, аңа кул кую датасы, теркәү номеры булырга тиеш. Шундый ук нигезләмәләр хәзерге вакытта гамәлдә булган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кабул ителгән 81 статьясындагы 4 пунктында да бар.

«Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларда урнаштырылган 218 һәм 895 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларының график сурәтләрендә югарыда күрсәтелгән реквизитлар юк, ә нәкъ менә аларга кул кую датасы һәм теркәү номерлары юк.

«2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары Рәсми порталда 03-03-415 номеры белән урнаштырылган иде. Карарның әлеге номеры «"2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында" Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы 2 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 февралендәге 155 номерлы һәм «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары белән аңа үзгәрешләр керткәндә соңрак яңадан кайтарылган. Ләкин Татарстан Республикасы Конституция суды мөрәҗәгатенә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан дәгъва белдерелә торган карарның 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы теркәү номеры белән рәсми тексты җибәрелде. «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының "2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль программасы турында" 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карарының 1, 2 нче кушымталарына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 15 ноябрендәге 2335 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга "Ишегалды стандарты" муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма

комитеты карарларында шикаять белдерелә торган карарның реквизиты сыйфатында шулай ук 415 номеры күрсәтелгән.

Татарстан Республикасы Конституция суды элегрәк билгеләп үткәнчә, норматив хокукый актларны рәсми рәвештә бастырып чыгару тәртибен үтәү — кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау механизмының аерылгысыз элементы, шуңа күрә кабул ителә торган актның тулы һәм төгәл реквизитларын аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле рәсми ресурсларда бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) шул исәптән график сурәтендә күрсәтү андый яклауның нәтиҗәлелеген күтәрүгә ярдәм итә һәм ул мәҗбүри (2017 елның 28 апрелендәге 73-П номерлы карар).

Мондый алым Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә дә тулысынча туры килә, ул үзләренең эчтәлеге һәм (яки) формасы буенча хокукый нормаларның формаль билгеләнеше, төгәллеге, ачыклыгы, бер мәгънәдә булуы һәм гамәлдәге хокукый җайга салу системасында аларның яраклашканлыгы критерийларына җавап бирми торган закон нигезләмәләре аларны төрле мәгънәдә аңлату һәм ирекле куллану мөмкинлеген булдыралар һәм шуның белән гражданнарның конституциячел хокукларын бозуга китерәләр дип берничә тапкыр билгеләп үтте (2012 елның 29 июнендәге 16-П номерлы, 2013 елның 14 маендагы 9-П номерлы карарлар һ.б.).

Югарыда күрсәтелгән хокукый позицияләрне исәпкә алып, дәгъва белдерелә торган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгарганда (халыкка җиткергәндә) китерелгән җитешсезлекләр аларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибен бозуны күрсәтә, әмма бу бозулар шикаять белдерелә торган актларның эчтәлеген гражданнар игътибарына җиткермәүне һәм аларның аның белән танышу мөмкинлеге булмавын расламыйлар. Әлеге актларның реквизитлары аларның график сурәтләрендә түгел, ә турыдан-туры «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтларында күрсәтелү факты үзеннән-үзе рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе буенча аларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану өчен җитәрлек нигез дип санала алмый, чөнки объектив рәвештә гражданнарга аларның хокукларына,

ирекләренә һәм законлы мәнфәгатьләренә кагылучы карала торган муниципаль хокукый актлар белән танышу мөмкинлеген гамәлгә ашыру өчен каршылыклар тудырмый.

Мондый хәлләрдә Татарстан Республикасы Конституция суды әлеге эштә мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарын, шулай ук «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарларын, аларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тәртибе буенча, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип танудан тыелып кала.

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция суды хокукый нормаларның эчтәлеген бәян иткәндә төгәлсезлектә, тулы булмауда һәм корректлы булмауда чагылган муниципаль хокукый актларның юридик техникасы камил булмау нормалар эшләү сыйфаты түбәнәюгә һәм хокукый җайга салуда тигезлек бозылуга китерүенә игътибар итәргә кирәк дип саный. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, шул исәптән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына, үзләре кабул итә торган муниципаль норматив хокукый

актларга игътибарлырак, төгәлрәк һәм җаваплырак карарга кирәклеген билгеләп үтү мөһим дип саный.

6. Россия Федерациясе Конституция Суды үзенең карарларында берничә тапкыр билгеләп үткәнчә, җирле үзидарәнең конституциячел билгеләнеше халыкның уртак көнкүреше территориясе буларак муниципаль берәмлек чикләрендә социаль-икътисадый бурычларны чишү белән берәттән кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен саклау һәм яклау, кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш өчен шартлар тудыру бурычларын нәтиҗәле гамәлгә ашыруда чагыла (2011 елның 29 мартындагы 2-П номерлы, 2015 елның 13 октябрендәге 26-П номерлы һәм 2016 елның 26 апрелендәге 13-П номерлы карарлар).

Мондый алым җирле үзидарә органнарының, шул исәптән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы чикләрендә урнашкан күпфатирлы йортларның ишегалды территорияләрен карап тоту һәм ремонтлау тәртибен регламентлаучы норматив хокукый актларның эчтәлеген һәм мәгънәсен алдан билгели.

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясындагы 35 пункты нигезләмәләре буенча муниципаль программа муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсешенең бурычлары, башкару сроклары, башкаручылары, ресурслары буенча һәм максатларга иң нәтиҗәле ирешүне һәм бурычларны хәл итүне тәэмин итүче планлаштырылган чаралар комплексын үз эченә алган стратегик планлаштыру документы булып тора. Әлеге Федераль законның 7 статьясындагы 13 пункты нигезендә программалы-максатчан принцип социаль-икътисадый үсешнең өстенлекләрен һәм максатларын билгеләүне, максатлары, гамәлгә ашыру сроклары буенча үзара бәйле муниципаль программалар әзерләүне һәм аларны финанслау күләмнәрен һәм чыганакларын билгеләүне аңлата.

Дәгъва белдерелә торган Программа нигезләмәләре эчтәлегеннән күренгәнчә, аны кабул итү сыйфатлы ял өчен уңайлы шартлар булдыру, даими

яшәү урыны янындагы территорияләрдә халыкның югары көнкүреш культурасын формалаштыру, халыкның ишегалды эчендәге территорияләрен төзекләндерүдә һәм тәртип саклауда катнашуы аша аның актив гражданлык позициясен формалаштыру максатларына бәйле.

Шуңа бәйле рәвештә Программада ишегалды территорияләрен комплекслы төзекләндерү буенча төп бурычлар билгеләнгән, шулай ук аларны тормышка ашыру чаралары һәм механизмы ачыкланган. Программаны тормышка ашыру механизмы элементларының берсе — аны үткәрүнең этаплылыгы, анда аларның ишегалды территорияләрен төзекләндерү буенча эшләр башкару планлаштырылган күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү кирәклеге дә кертелә.

Федераль дәрәҗәдә дә, республика дәрәҗәсендә дә Программаны гамәлгә ашыру өчен күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү критерийларына таләпләр билгеләнмәгәнлектән, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, үзенә бирелгән дискрецион вәкаләтләр кысаларында эш итеп, аларны мөстәкыйль билгеләгән. Шуның белән бергә Программаның эчтәлеге максатларга ирешү нәтиҗәләре һәм анда билгеләнгән конкрет бурычларны хәл итү белән тәңгәл килергә тиеш.

6.1. Программаның мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган 8 бүлегендәге 1 пунктында каралганча, беренче чиратта Программаны гамәлгә ашыру «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга ярдәм итү фонды турында» 2007 елның 21 июлендәге 185-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә комплекслы капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортлар өчен каралган; йортларның әлеге төркем эчендәге күпфатирлы йортларның чираты гомуми тәртиптә исәпләнгән сан рейтингы зурлыгы нигезендә формалаштырылган.

Программаның 3 бүлегендә каралганча, Программа башка программалар һәм чаралар белән үзара бәйләнештә гамәлгә ашырыла, алар кысаларында инфраструктура үзгәрешләре тормышка ашырыла. Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган нигезләмәне

күрсәтелгән аспектта Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясы нигезләмәләре, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 8 статьялары белән, шулай ук аларны үстерү өчен кабул ителгән «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программаны раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән системалы бердәмлектә карарга кирәк. Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының күрсәтелгән карарының V бүлегендәге 1 пунктының 17 пунктчасы нигезендә күпфатирлы йортка комплекслы капиталь ремонт үткәргәндә йорт яны территориясен төзекләндерү (балалар өчен уен мәйданчыклары һәм спорт комплекслары урнаштыру белән) күздә тотыла.

Шулай итеп, йорт яны территорияләрен саклау һәм яңарту өлкәсендә төп юнәлеш — ишегалды территорияләрен комплекслы төзекләндерү икәнен истә тотып, әлеге өстенлекне кертү капиталь ремонт инде үткәрелгән күпфатирлы йортларда финанс кертемнәренең нәтиҗәлелеге һәм төзекләндерү элементларының сакланышы фикерләренә нигезләнгән, чөнки бу очракта гына күпфатирлы йортка капиталь ремонтны, аның йорт яны территориясен төзекләндерүне дә кертеп, тулысынча һәм комплекслы төгәлләү турында сүз барырга мөмкин, бу үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый һәм, димәк, Программаның 8 бүлегендәге 1 пунктының дәгъва белдерелә торган нигезләмәсе мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән аспектта Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми. Мондый алым 1966 елның 16 декабрендәге Граждан һәм сәяси хокуклар турында халыкара пактны гамәлгә ашыруны тикшереп торучы Кеше хокуклары буенча комитетның хокук куллану практикасына туры килә, аның нигезендә закон каршында тигез булу хокукы һәм бернинди дискриминациясез законны тигез яклау хокукы

мөрәҗәгатьтәге теләсә кайсы аерымлык дискриминацияле дигәнне аңлатмый, шуңа күрә резонлы һәм объектив критерийларга нигезләнгән дифференциация Пактның 26 статьясы мәгънәсе буенча тыелган дискриминация белән бер үк түгел (Комитетның 1987 елның 9 апрелендәге 182/1984 номерлы карарының 13 пункты).

6.2. Аңлылык (С), коммуникацияләр (К) һәм куркынычсызлык (V) коэффициентларына (8 бүлекнең 2 пункты) бәйле рәвештә эшләр башкару өчен күпфатирлы йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратын билгеләү критерийларының билгесезлеге турындагы мәсьәләне карап, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

6.2.1. Дәгъва белдерелә торган нормада аңлылык (С) коэффициенты күпфатирлы йортта күпфатирлы йорт Советының булуына бәйле рәвештә куелган: әгәр күпфатирлы йорт Советы сайланган булса, аңлылык (С) коэффициенты 0,5 кә тигез, әгәр ул сайланмаган булса, аңлылык (С) коэффициенты 1 гә тигез.

Россия Федерациясе Торак кодексының 161.1 статьясындагы 1 өлеше нигезендә, әгәр әлеге йортта дүрттән артык фатир булса һәм шул ук вакытта анда торак милекчеләре ширкәте оештырылмаса яисә әлеге йорт торак кооперативы яисә башка төрле кулланучылар кооперативы тарафыннан идарә ителмәсә, күпфатирлы йортта урыннарның милекчеләре күпфатирлы йортның советын сайларга бурычлы.

Дәгъва белдерелә торган норманың 2 пункты нигезләмәләре күпфатирлы йортларның чиратлылыгы рейтингның минималь күрсәткечләреннән максималь күрсәткечләргә нисбәте буенча (ягъни сан күрсәткече азрак булган саен, Программа нигезендә эшләр шулкадәр алданрак башкарыла) аралау юлы белән билгеләнә. Шикаять белдерелә торган норманың сүзгә-сүз аңлатмасыннан күренгәнчә, күпфатирлы йорт Советы сайланган йортлар түбән санлы рейтинг җыялар, ә, мәсәлән, йорт белән идарә итү ысулы буларак торак милекчеләре ширкәте сайланган йортлар белән чагыштырганда да, димәк, Программага алданрак эләгәләр. Татарстан Республикасы Конституция суды мондый алым

нигезле дип танылa алмый дип саный, чөнки әлеге Кодексның башка нормалары белән үзара бәйләнештә Россия Федерациясе Торак кодексының 161.1 статьясы эчтәлегеннән аңлашылганча, күпфатирлы йорт Советы күпфатирлы йортта урыннар милекчеләренең үз-үзләрен оештыру төрләреннән берсе генә булып тора. Шуңа бәйле рәвештә карала торган хокукый җайга салу, асылда, йорт белән идарә итү ысулы буларак идарәче компанияне сайлаган күпфатирлы йортларга өстенлек бирүгә юнәлдерелгән, бу исә акылга ярашлылык һәм гаделлек, юридик тигезлек принципларына җавап бирми, һәм бу, Программада куелганга караганда, турыдан-туры каршылыклы максатларга китерергә мөмкин, чөнки үз эчтәлегеннән чыгып, күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулы буларак торак милекчеләре ширкәтен яисә торак кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы белән идарә итүне сайлаган күпфатирлы йортларда урыннарның милекчеләре өчен хокукый хәлдә нигезсез дифференциация тудыра.

Моннан тыш, Россия Федерациясе Торак кодексының 161.1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә, әгәр календарь елы дәвамында анда урыннарның милекчеләре тарафыннан күпфатирлы йорт советын сайлау турында карар кабул ителмәсә яки тиешле карар гамәлгә ашырылмаган булса, җирле үзидарә органы өч айлык срокта күпфатирлы йортта урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышын чакырта, аның көн тәртибенә бу йортта күпфатирлы йорт советын, шул исәптән бу йорт советының рәисен сайлау турында яки бу йортта торак милекчеләре ширкәтен оештыру турында мәсьәләләр кертелә. Димәк, үзенең сүзгә-сүз атамасына — «аңлылык коэффициенты», шулай ук Программада каралган бурычларның берсенә, ә атап әйткәндә — халыкны үзләренең күпфатирлы йортлары белән идарә итүгә тартуга карамастан, күрсәтелгән коэффициент, киресенчә, урыннарның милекчеләре үзләре яши торган күпфатирлы йорт белән идарә итү эшләрендә активлык һәм аңлылык күрсәтмәгән күпфатирлы йортларда милекчеләре күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау буенча мөстәкыйль

инициатива күрсәткән йортлардагыга караганда элегрәк Программа буенча эшләр башкару өчен мөмкинлек тудыра.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды шикаять белдерелә торган хокукый җайга салу күпфатирлы йорт Советы сайланган күпфатирлы йорт милекчеләрен Программага кертелгән күпфатирлы йортларның башка милекчеләренә карата күрә торып тигезсез хәлгә куя дигән нәтиҗәгә килә.

Шулай итеп, күпфатирлы йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратын билгеләү критерийларының билгесезлеге өлешендә Программаның дәгъва белдерелә торган 8 бүлегендәге 2 пункты, күпфатирлы йорт Советын сайлауга бәйле рәвештә (аңлылык (С) коэффициенты) гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килә.

6.2.2. Шикаять белдерелә торган нормада коммуникацияләр (К) коэффициенты хисаплар бирү буенча (ягу сезонына, запросларга, мәгълүматны ачарга һ.б. әзерләнгәндә) җирле үзидарә органнарының күпфатирлы йорт адресына карата кисәтүләре булуга, шулай ук күпфатирлы йорт вәкилләренең җирле үзидарә органнары үткәрә торган чараларда (киңәшмәләрдә, семинарларда, очрашуларда һ.б.) даими катнашучылар булу-булмавына бәйле рәвештә куелган. Кисәтүләр булса, шулай ук әлеге чараларда катнашмаган очракта, коммуникацияләр (К) коэффициенты 1 гә тигез, кисәтүләр булмаган очракта коммуникацияләр (К) коэффициенты 0,5 кә тигез.

Дәгъва белдерелә торган норманы анализлау әлеге коэффициентны билгеләү хокукый нигезгә ия түгел дигән нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә, чөнки күпфатирлы йортка карата җирле үзидарә органының кисәтүләрен алырга мөмкин булган хисапларны тапшырганда күпфатирлы йортның бозулары дәрәҗәсен дөрес бәяләргә мөмкинлек бирми, җирле үзидарә органнары үткәрә торган чараларда катнашу даимилеге төшенчәләрен ачмый, шулай ук аларда катнашуны раслау формасын билгеләми.

Шуңа бәйле рәвештә шикаять белдерелә торган норма, аның сүзгә-сүз аңлатмасыннан чыгып, хокук куллану органына әлеге коэффициентның эчтәлеген һәм күрсәткечләрен үзенчә исәпкә алырга һәм бәяләргә мөмкинлек бирә торган вариатив характерга ия, бу җирле үзидарә органының конкрет күпфатирлы йортларда яшәүчеләргә мөнәсәбәте кебек субъектив фактор булуын, димәк, Программаны гамәлгә ашырганда мондый күпфатирлы йортның чиратлылыгын билгеләү булуын да күрсәтә.

Татарстан Республикасы Конституция суды, мондый алымны нигезле дип танырга ярамый, чөнки дәгъва белдерелә торган норма эчтәлегенең билгесезлеге хокук куллану процессында чикләнмәгән каралуга юл куя һәм законсызлыкка, димәк, тигезлек һәм закон өстенлеге принципларының бозылуына китерә дип саный.

Алай гына да түгел, мондый алым норматив нигезләмәләргә карата куела торган ачыклык һәм каршылыксызлык таләпләре белән туры килми, аларда законның гамәлдә булу механизмы тиешле хокук мөнәсәбәтләре субъектларына конкрет норматив нигезләмәләр эчтәлегеннән яисә норматив нигезләмәләрнең күзгә күренеп торган үзара бәйләнешендә булган системадан чыгып аңлаешлы булырга тиешлеге, чөнки конституциячел тигез хокуклылык хокукый норманы барлык хокук кулланучылар тарафыннан бертөрле аңлау һәм аңлату шарты белән генә тәэмин ителергә мөмкин булуы күздә тотыла (Россия Федерациясе Конституция Судының 2013 елның 27 июнендәге 15-П номерлы, 2013 елның 23 декабрендәге 29-П номерлы, 2014 елның 22 апрелендәге 12-П номерлы һ.б. карарлар).

Шулай итеп, Программаның мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган 8 бүлегендәге 2 пункты, Программаны гамәлгә ашырганда, әлеге мәсьәләне хәл итүне хокук кулланучы каравына калдырып, күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү өчен коммуникацияләр (К) коэффициентының билгесезлеге өлешендә, гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза һәм, димәк, Татарстан

Республикасы Конституциясенә, аның 2, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 32 һәм 55 статьяларына туры килми.

6.2.3. Дәгъва белдерелә торган нормада куркынычсызлык (V) коэффициенты милекчеләрнең күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга ризалыгына бәйле итеп куелган — әгәр күпфатирлы йортта видеокүзәтү урнаштыру өчен кворум җыелса, куркынычсызлык (V) коэффициенты 0.5 кә тигез, әгәр кворум җыелмаган булса, куркынычсызлык (V) коэффициенты 1 гә тигез.

Россия Федерациясе Торак кодексының 161 статьясындагы 1.1 өлеше нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең гомуми милкен тиешле тәртиптә тоту Россия Федерациясе законнары таләпләре нигезендә башкарылырга тиеш һәм күпфатирлы йортның ышанычлылыгына һәм иминлегенә, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлегенә, физик һәм юридик затлар мөлкәтенә, дәүләт һәм муниципаль мөлкәтнең иминлегенә һәм башкаларга карата таләпләрне үтәүне тәэмин итәргә тиеш. Уртак милекне карап тотуның хокукый шартлары Россия Федерациясе Торак кодексының 39 статьясындагы өченче өлеше буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортта уртак милекне карап тоту кагыйдәләре белән билгеләнгән, алар нигезендә урыннар милекчеләре уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча гамәлләрне мөстәкыйль башкарырга яки күпфатирлы йорт белән идарә итүнең сайланган ысулын исәпкә алып, уртак милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм эшләр башкару өчен башка затларны җәлеп итәргә хокуклы (12 пункт), шулай ук гомуми җыелышта хезмәтләр һәм эшләр исемлеген, аларны күрсәтү һәм башкару шартларын, аларны финанслау күләмен расларга тиешләр (17 пункт).

Татарстан Республикасы Конституция суды күрсәткәнчә, күпфатирлы йортны видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү мәсьәләләрен хәл итү мондый йорттагы урын милекчеләренең бары тик аерым хокукы гына булып тора. Шул ук вакытта видеокүзәтү системасын кертү турындагы карар, видеокүзәтү

хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм аның өчен түләү күләме кебек үк, әлеге милекчеләрнең гомуми җыелышында билгеләнгән тәртиптә кабул ителергә һәм тиешле беркетмә белән рәсмиләштерелергә тиеш (2019 елның 25 ноябрендәге 86-П номерлы карар).

Дәгъва белдерелә торган Программа, аны гамәлгә ашырганда, күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләгәндә бу хәлне исәпкә алса да, күпфатирлы йортларның милекчеләренә үзләренең күпфатирлы йортларын видеокүзәтү системасы белән тәэмин итү бурычын йөкләми.

Шуның белән бергә, шикаять белдерелә торган хокукый нигезләмә Программаның хокукый статусыннан һәм аның эчтәлегеннән килеп чыга, аның нигезендә Программаның нәтиҗәлелеге шул исәптән гражданнар милкенең һәм гомуми йорт милкенең куркынычсызлыгын һәм сакланышын арттыру хисабына, шулай ук аларга контрольне көчәйтү, төзекләндерү объектлары өчен халыкның җаваплылыгын арттыру хисабына да ирешелә. Моннан тыш, Программаны финанслау, шул исәптән, җирле бюджет акчалары хисабына да гамәлгә ашырыла. Мондый шартларда Татарстан Республикасы Конституция суды, Программаны гамәлгә ашырганда күпфатирлы йортларның чиратлылыгын билгеләү өчен Программаның 8 бүлегендәге 2 пунктында куркынычсызлык (V) коэффициенты булу, шулай ук Программаның 9 бүлегендәге 2 пунктының «Б» пунктчасында күрсәтелгән күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгына карап, күпфатирлы йортны еллык Планга кертү турындагы таләпнең булуы Программа кысаларында башкарылган йорт яны территорияләрен төзекләндерү эшләренең үзенчәлекле сакланыш гарантиясе булып тора дип саный, бу гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый.

Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституция суды шуңа игътибар итә: дәгъва белдерелә торган Программаның хокукый эчтәлеге күпфатирлы йорт ишегалдында видеокүзәтү системасы инде урнаштырылган очракларда куркынычсызлык (V) коэффициентын исәпләргә мөмкинлек бирми,

бу исә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан аңа тиешле төзәтмәләр кертүен таләп итә.

7. Программаның 9 бүлегендәге 1 пункты нигезләмәләрен, аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган һәм күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан аны гамәлгә ашыру еллык Планына әлеге йортны кертү өчен Программада катнашу турында Мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү турындагы таләпне үз эченә алган дәрәҗәдә бәяләп, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләргә игътибар итәргә кирәк дип саный.

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 9 статьясындагы 1 өлешенең өченче абзацындагы һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре буенча муниципаль берәмлекләрнең бюджет вәкаләтләренә, аерым алганда, җирле бюджет проектын төзү һәм карау, аны раслау, үтәү, тикшереп тору, шулай ук аның үтәлеше турындагы хисапны төзү һәм раслау керә. Шундый ук нигезләмәләр «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законында да бар (7 статьяның 1 өлешендәге 9 пункты, 16 статьяның 1 өлешендәге 1 пункты, 22 статьяның 8 өлешендәге 2 пункты һәм 33 статьяның 4 өлеше).

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турында нигезләмәнең 25 статьясындагы 2 пункты һәм 34 статьясындагы 1 пункты нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты (район Башкарма комитеты җитәкчесе аша) агымдагы елның 15 ноябреннән дә соңга калмыйча район Советы каравына чираттагы финанс елына һәм план чорына, шул исәптән муниципаль программаларга нигезләнгән район бюджеты турындагы карар проектын кертә.

Шикаять белдерелә торган норманы югарыда күрсәтелгән Нигезләмә нормалары белән, шулай ук Программаның үзенең, аны финанслау шул исәптән

җирле бюджет акчалары хисабына гамәлгә ашырыла, финанслау күләме ел саен билгеләнә, Программаны гамәлгә ашыруга сарыф ителә торган акчалар бюджет финанславы мөмкинлекләреннән чыгып ачыклана (4 бүлек) дигән башка нигезләмәләре белән системалы бәйләнештә карап, Татарстан Республикасы Конституция суды, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Программаны гамәлгә ашыруның чираттагы елына финанслау лимиты кысаларында күпфатирлы йортлар кертелә торган Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау срокларын билгеләү мәсьәләсендә чикләнмәгән ирекккә ия түгел, чөнки аны раслау чираттагы финанс елына Зеленодольск муниципаль районы бюджетын әзерләү һәм раслау срокларына бәйле дип билгеләп үтә.

Югарыда күрсәтелгән бюджетны планлаштыруга кагылышлы нигезләмәләр Программаның дәгъва белдерелә торган 9 бүлегендәге 1 пунктында булган күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан әлеге йортны Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планына кертү өчен анда катнашу турында ел саен Мөрәҗәгать җибәрү турындагы таләпне дә билгели. Моннан тыш, Программаның 9 бүлегендәге 3 пункты нигезендә, еллык Планны финанслау лимитлары Мөрәҗәгатьләр булган барлык күпфатирлы йортларга карата Программаны гамәлгә ашыру эшләрен башкарырга мөмкинлек бирмәгән очракта, Планга Мөрәҗәгатьләр булган йортлар саныннан рейтингның иң зур күрсәткече булган күпфатирлы йортлар кертелми. Бу очракта мондый йортны киләсе еллык Планга кертү мөмкинлеге, гомуми тәртиптә санлы рейтинг күләменнән чыгып, яңа формалаштырыла торган чират белән билгеләнә. Шул ук вакытта, Программаның 7 бүлеге нигезендә аңа Зеленодольск шәһәре территориясендә урнашкан, йорт яны территорияләре норматив хокукый актлар таләпләренә туры китереп, асфальт катламын торгызу (ремонтлау, урнаштыру) буенча эшләргә мохтаҗ булган барлык күпфатирлы йортлар да кертелүен, ә еллык Планга милекчеләре тиешле Мөрәҗәгатьләр биргән күпфатирлы йортлар кертелүен исәпкә алырга кирәк.

Шулай итеп, Программаның 9 бүлегендәге 1 пунктының карала торган нигезләмәсе, ул аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган дәрәҗәдә, шулай ук әлеге карарда ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планына әлеге йортны кертү өчен анда катнашу турында Мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү таләбе булган дәрәҗәдә үзеннән-үзе кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең ул күрсәткән аспектта конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый. Моның белән Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан Программаны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау срокларын төгәлләштерү өлешендә, шикаять белдерелә торган нигезләмәгә тиешле төгәллек кертү юлы белән, әлеге хокукый җайга салуны камилләштерү мөмкинлеге юкка чыгарылмый.

8. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә күпфатирлы йорттагы урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышы күпфатирлы йорт белән идарә итү органы булып тора, ул күпфатирлы йорт белән идарә итү максатларында көн тәртибендәге мәсьәләләр буенча фикер алышу һәм тавышка куелган мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү юлы белән үткәрелә (44 статьяның 1 өлеше). Әлеге статьяның 2 өлешендәге 2.1 пункты нигезендә күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең гомуми җыелышы вәкаләтләренә күпфатирлы йорт урнашкан һәм күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең гомуми милкенә караган җир кишәрлеген төзекләндерү, шул исәптән күрсәтелгән җир кишәрлегендә яшелләндерү һәм төзекләндерү элементларын урнаштыру, аларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү турында карарлар кабул итү керә. Гомуми җыелыш үткәрүне оештыру (45 статьяның 2, 4 һәм 5 өлешләре) һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен беркетмә белән рәсмиләштерү (46 статья) бурычы йөкләнгән күпфатирлы йортның урын милекчеләре генә мондый җыелышның инициаторы булып тора ала.

Торак законнарының китерелгән нигезләмәләрен исәпкә алып, дәгъва белдерелә торган Программаның 9 бүлегендәге 2 пункты, асылда, аны еллык Планга кертү турында карар кабул итү өчен күпфатирлы йорттагы урын милекчеләренең гомуми җыелышына тикшерүгә чыгарылырга тиешле мәсьәләләр даирәсен билгели. Шул ук вакытта куелган мәсьәләләр буенча тавыш бирүнең гомуми җыелыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә торган нәтиҗәләре, шикаять белдерелә торган нигезләмәдән чыгып, күпфатирлы йортны еллык Планга кертү өчен ачыктан-ачык белдерелгән ризалык дип санала ала, бу үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый һәм, димәк, Татарстан Республикасы Конституциясенә каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 һәм 104 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга:

— Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының 2018 елның 29 мартындагы 279 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясындагы 10 өлешен, чөнки ачыкланган конституциячел-хокукый мәгънәсен исәпкә алып, әлеге норма норматив хокукый актны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) датасын күрсәтү мәҗбүри булган һәркем өчен бер булган тәртипне сакламау мөмкинлегенә юл куймый;

— «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы, «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль программасы турында» 2016 елның 25 февралендәге 03-03-415 номерлы Татарстан

Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 2 февралендәге 218 номерлы һәм «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 25 февралендәге 415 номерлы карары белән расланган «2016—2026 елларга “Ишегалды стандарты” муниципаль адреслы программасына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 11 апрелендәге 895 номерлы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карарлары, аларны рәсми бастырып чыгару тәртибе буенча;

— Программаның 8 бүлегендәге 1 пункты, аның нигезендә, беренче чиратта, аны гамәлгә ашыру комплекслы капиталь ремонт ясалган күпфатирлы йортлар өчен каралган;

— Программаның 8 бүлегендәге 2 пункты, күпфатирлы йортта видеокүзәтү системаларын урнаштыруга кворум җыелуга бәйле рәвештә, Программа буенча күпфатирлы йортның чиратлылыгын билгеләгәндә, санлы рейтинг күләменә йогынты ясый торган куркынычсызлык (V) коэффициентын билгеләү өлешендә;

— Программаның 9 бүлегендәге 2 пунктының «Б» пунктчасы, ул күпфатирлы йортны, күпфатирлы йортта видеокамералар урнаштыруга милекчеләрнең ризалыгыннан чыгып, еллык Планга кертү турындагы таләпне үз эченә ала;

— Программаның 9 бүлегендәге 1 пункты, ул аны гамәлгә ашыруның еллык Планын раслау датасын билгеләми торган дәрәҗәдә, шулай ук күпфатирлы йорт милекчеләре тарафыннан гамәлгә ашыруның еллык Планына әлеге йортны кертү өчен Программада катнашу турында Мөрәҗәгатьне ел саен җибәрү турындагы таләпне үз эченә алган дәрәҗәдә;

— Программаның 9 бүлегендәге 2 пункты, аның нигезендә мөрәҗәгатьтә күпфатирлы йортны еллык Планга кертүгә ачыктан-ачык белдерелгән ризалык булырга тиеш.

2. Программаның 8 бүлегендәге 2 пунктын, анда билгеләнгән аңлылык (С) һәм коммуникацияләр (К) коэффициентларына бәйле рәвештә, күпфатирлы

йортлар өчен Программаны гамәлгә ашыру чиратлылыгын билгеләү критерийларының билгесезлеге өлешендә, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип таныргa.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына — Татарстан Республикасы Конституциясе таләпләреннән чыгып һәм Татарстан Республикасы Конституция судының әлеге Карарда бәян ителгән шул таләпләргә нигезләнгән хокукый позицияләрен исәпкә алып — Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә гамәлдә булган хокукый җайга салуга әлеге Карардан килеп чыга торган кирәкле үзгәрешләрне кертергә.

4. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

5. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 72 статьясы нигезендә әлеге Карар «Ватаным Татарстан» һәм «Республика Татарстан» газеталарында кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгарга тиеш.

**№ 89-П**

**Конституционный суд Республики Татарстан**